**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Туера авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

13 ноябрь, 2025 ел № 1

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 45,69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлегенең 29.10.2019 ел 49/2 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары нигезендә, 2025 елның 13 ноябрендә Туера авлында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

«2026 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Туера авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең)сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Туера авылының Кызыл Армия урамында янгын гидранты урнаштыру);
- урамнарны яктырту җайланмасы(СИП сузу, Туера авылының Кызыл Армия урамы буенча яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 35 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 20 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 20 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Таулар авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Туера авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең)сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Туера авылының Кызыл Армия урамында янгын гидранты урнаштыру);
- урамнарны яктырту җайланмасы(СИП сузу, Туера авылының Кызыл Армия урамы буенча яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)ны хәл итүгә юнәлдерергә.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Туера авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Туера авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова